**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 июнь № 426

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 7 декабрь, 922 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 7 декабрь, 922 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 11 май, 295 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган стационар, ярымстационар формалы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында дәүләт хезмәте күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларында:

6 пунктның 6.4 пунктчасы үз көчен югалтуын танырга;

7 пунктта:

8.18 пунктчаны 7.18 пунктча дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле 7.19 пунктча өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «7.19. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районында «Шәфкатьлелек үзәге» ХСХКҮ» ДАСХКУ социаль-тернәкләндерү бүлеге | 3,56»; |

9 пунктны, 9.1 пунктчаны туры килү буенча 8 пункт, 8.1 пунктча дип санарга;

әлеге карар белән расланган стационар һәм ярымстационар формалы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында койка-көн саны:

Арча муниципаль районы юлында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районында «Өмет» инвалидларны тернәкләндерү үзәге» дәүләт бюджет

учреждениесе (алга таба – ДБУ) сүзләрен « Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районында «Шәфкатьлелек үзәге» ХСХКҮ» ДАСХКУ социаль-тернәкләндерү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

Зеленодольск муниципаль районы юлында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Идел» республика инвалидларны социаль тернәкләндерү үзәге» ДБУ» сүзләрен «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Идел» республика инвалидларны социаль тернәкләндерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – ДБУ)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карараның гамәле 2016 елның 19 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков